**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлеге БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Юхмачинского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

Адресы: 422885, ТР, Әлки районы, Юхмачы авылы, Ленин урамы ,1а
Тел./факс 8(84346) 74-224

Адрес:422885, РТ, Алькеевский район, с. Юхмачи, ул.Ленина, д.1а
тел./факс 8(84346) 74-224

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Юхмачы ав. КАРАР

2025 елның " 13 " октябре № 46

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 22 мартындагы 16-нчы номерлы карарына «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Юхмачы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урынын булдыру, аның урнашуы турында кулланучыларга мәгълүмат бирү турында» үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.12.2020 елның 2314-нче карары «Җитештерү һәм куллану калдыклары белән тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә эш итү кагыйдәләрен раслау турында» (14 март 2024 ел үзгәрешләр кертеп)" нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР КАБУЛ ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 22 мартындагы 16-нчы номерлы Карарының «Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлеге территориясендә терекөмешле эшкәртелгән лампалар туплану урыннары турында" 4 пунктынын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, шулай ук мәгълүматны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы

авыл җирлеге Җирле үзидарә органнары биналарындагы мәгълүмат стендларында (стойкаларында) урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә».

2. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның «30» июлендәге 32-нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында: http://alkeevskiy.tatarstan.ru/ урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Юхмачы авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе А.В.Тутеров